**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы авыл җирлеге Башкарма комитеты**

**КАРАРЫ**

20 декабрь 2021 ел № 41

«ТР Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясендә 2022 – 2025 елларга кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү Программасын раслау турында»

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнарга, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен шартлар тудыру максатларында, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясендә 2022 – 2025 елларга кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү Программасын расларга (Программа кушып бирелә).
2. 2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең рәсми сайтында http://kukmor.tatarstan.ru адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Кукмара муниципаль районы
Зур Сәрдек авыл җирлеге башкарма
комитеты җитәкчесе Ф.М.Фаттахов

РАСЛАНГАН

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 20 декабрендәге 41 номерлы карары белән

**Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясендә 2022 – 2025 елларга кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү программасы паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясендә 2022 – 2025 елларга кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү программасы» |
| Программаның заказчысы: | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| Программаны эшләүче: | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| Программаның нигезе: | «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон,<br>«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы |
| Программаның максатлары: | - Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлеге буенча кече бизнесны үстерү өчен оптималь шартлар тудыру<br>- кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү исәбенә икътисади күтәрелеш һәм халыкны эш белән тәэмин итү проблемаларын хәл итү |
| Программаның бурычлары: | 1. Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге буенча кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү инфраструктурасын үстерү;<br>2. Барлык дәрәҗәдәге бюджетларга кече һәм урта бизнестан салым керемнәрен арттыру;<br>3. Кече һәм урта эшмәкәрлекнең инвестицион активлыгын арттыру;<br>4. Җир мөнәсәбәтләрен камилләштерү һәм җир базарын үстерү; |

| | |
|---|---|
| | 5. Минималь хезмәт хакы дәрәҗәсен минималь куллану бюджеты бәясеннән дә ким булмаган күләмдә тәэмин итү;<br>6. Бизнес-Хакимият-Җәмгыять коммуникацияләре системасын үстерү;<br>7. Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә районның балансланган икътисади сәясәтен исәпкә алып, кече бизнес өлкәсенә эш белән мәшгуль булмаган халыкны җәлеп итү өчен өстәмә стимуллар булдыру;<br>8. Кече бизнес өлкәсендә мәшгуль кешеләрне социаль яклау белән тәэмин итү.<br>9. Халыкның тормыш шартларын яхшыртуда кече бизнесның ролен арттыру. |
| Программаны финанслау күләме | Чараларны тормышка ашыру өчен Зур Сәрдек авыл җирлеге бюджеты хисабына финанслау күләме каралмаган.<br>Зур Сәрдек авыл җирлегенең кече бизнес субъектларының үз акчалары |

**Программа бүлекләре**

1. Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлекнең торышын анализлау.
2. Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү проблемалары һәм аларны программа методлары белән хәл итү кирәклеген нигезләү.
3. Программаны ресурслар белән тәэмин итү
4. Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелегенә кᴏтелгән бәя
5. Эшмәкәрлек эшчәнлегенең өстенлекле төрләре.
6. Программаның төп чаралары эшләнгән юнәлешләр
7. Программаны тормышка ашыру механизмы.
8. Зур Сәрдек авыл җирлеге буенча 2022 – 2025 елларга кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү Программасының төп чаралары.

## 1. Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлекнең торышын анализлау

Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү хуҗалык итүнең базар системасының аерылгысыз элементы булып тора. Базар икътисады алга киткән илләрдә кече эшмәкәрлек дәүләт икътисадының нигезе, хуҗалык үсешенең двигателе булып тора, чөнки бу теләсә кайсы җәмгыятьнең эшлекле тормышының иң динамик һәм сыгылмалы формасы.

Хуҗалык итүнең базар системасы шартларында кече һәм урта эшмәкәрлекнең аерым ролен түбәндәге факторлар билгели:

- үз тормышын һәм лаеклы тормыш дәрәҗәсен мөстәкыйль тәэмин итүче һәм гражданлык җәмгыятенең тотрыкландыручы төп сәяси көче булган урта сыйныф өлешен арттыру;

- кече һәм урта эшмәкәрлек секторында яңа эш урыннары булдыру өчен зур потенциал булу, җәмгыятьтә эшсезлек дәрәҗәсен һәм социаль киеренкелекне киметү;

халыкның төп массасының иҗтимагый психологиясенең һәм тормыш ориентирларының үзгәрүе;

- кече һәм урта эшмәкәрлекнең сыгылмалылыгы һәм җитештерү структурасын тиз арада үзгәртеп кору, яңа технологияләр һәм фәнни эшләнмәләрне оператив рәвештә булдыру һәм куллану сәләте.

Шуның белән бәйле рәвештә Кукмара районы Зур Сәрдек авыл җирлеге буенча кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү Программасын эшләү һәм тормышка ашыру зарурлыгы туа.

Әлеге Программа «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнде.

Кече эшмәкәрлек 2021 елның 01 декабренә торышы буенча түбәндәге күрсәткечләр белән характерлана:

| № т/б | Күрсәткечләр исеме | Үлчәү берәмлекләре | 2020 ел хисап | 2021 ел хисап |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Зур Сәрдек авыл җирлеге буенча теркәлгән кече предприятиеләр саны | берәмлек | 56 | 60 |
| 2 | Шулардан: | | | |
| | Авыл хуҗалыгы | берәмлек | 20 | 23 |
| | Сәүдә һәм җәмәгать туклануы | берәмлек | 22 | 22 |
| 3 | Шәхси эшмәкәрләр сыйфатында теркәлгән физик затлар саны | кеше | 15 | 15 |
| | кече предприятиеләр | берәмлек | 22 | 22 |
| | юридик зат белеме булмаган физик затлар | берәмлек | 0 | 0 |
| 4 | Кече предприятиеләр буенча (тышкы совместительләрдән башка) хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны | кеше | 185 | 200 |
| | шул исәптән икътисад тармаклары буенча: | | | |
| | Авыл хуҗалыгы | кеше | 45 | 50 |
| | Сәүдә һәм җәмәгать туклануы | кеше | 140 | 150 |

## 2. Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү проблемалары һәм аларны программа методлары белән хәл итү кирәклеген нигезләү

Хәзерге вакытта Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлегендә кече эшмәкәрлек өлкәсендә элеккегечә хәл ителмәгән проблемалар бар.

Җирлектә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлеге үсешен тоткарлаучы факторлар булып түбәндәгеләр тора:

- инвестицион ресурслардан файдалану кыенлыгы, кредит ресурсларының һәркем файдалана алырлык булмавы фонында үз финанс чараларың җитмәве;
- гамәлдәге законнардагы үзгәрешләр турында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мәгълүматы аз булу, административ киртәләр һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашырганда хакимият органнарының төгәл регламентлары булмау;
- шәһәрнең кече предприятиеләрендә квалификацияле эшче белгечлекләргә кытлык булу.

Эшмәкәрлек эшчәнлеге субъектлары тарафыннан карарлар кабул итүне һәм гамәлгә ашыруны таләп итә торган проблемалар:

- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының социаль җаваплылыгы югары булмау (ялланган хезмәткәрләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрен рәсмиләштермәү, хезмәткә түләү фондын киметү һәм аны «конверт» формасында түләү, мәҗбүри пенсия иминияте һәм социаль иминиятләштерү турындагы законнарны үтәмәү);
- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлеген алып бара торган икътисад тармакларының диспропорциясе (сәүдәнең шактый үсеше фонында җитештерүнең җитәрлек дәрәҗәдә үсмәве).

Зур Сәрдек авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне алга таба да үстерү һәм булган каршылыкларны урыннарда мәгълүмати, белем бирү, консультация, финанс юнәлешләрендә комплекслы һәм адреслы ярдәм күрсәтү юлы белән аны үстерү өчен уңайлы шартлар тудыру буенча максатчан эш нигезендә, эшлекле элемтәләрне һәм кооперацияне җайга салу юлы белән, шулай ук эшмәкәрләрдә коллектив ихтыяҗ туарга мөмкин булган башка аспектларда ярдәм күрсәтү юлы белән генә җиңеп чыгу мөмкин. Программа билгеләнгән максатларга ирешү өчен җирле хакимият органнарының, шулай ук дәүләтнеке булмаган оешмаларның көчләрен берләштерергә һәм оптимальләштерергә мөмкинлек бирәчәк.

## 3.Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Чараларны тормышка ашыру өчен Зур Сәрдек авыл җирлеге бюджетында финанслау чыганаклары каралмаган.

Финаслау күләмнәре – Зур Сәрдек авыл җирлегенең кече бизнес субъектларының үз акчалары

## 4. Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелегенә көтелгән бәя

Программа Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне алга таба үстерү өчен уңай шартлар тудыруга юнәлдерелгән чаралар комплексын үз эченә ала.

Программаны үтәү түбәндәгеләргә ярдәм итәчәк:

- районда икътисадый һәм социаль стабильлекнең иң мөһим элементларыннан берсе буларак, кече һәм урта эшмәкәрлекнең тотрыклы эшчәнлеген барлыкка китерүне стимуллаштыра торган уңай икътисадый мохит формалаштыру;
- кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү темпларын арттыру, эшчәнлек өлкәләрен киңәйтү һәм кече предприятиеләрне икътисадый яктан ныгыту;
- эш белән тәэмин итүнең өстәмә мөмкинлекләре барлыкка килү, кече эшмәкәрлектә эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәт хакын арттыру;
- товар базарын конкурентлыкка сәләтле продукция һәм җирле производство хезмәтләре белән тәэмин итү;
- кече һәм урта эшмәкәрлекнең социаль җаваплылыгы арту.

## 5 . Эшмәкәрлек эшчәнлегенең өстенлекле төрләре

Җирлек халкының тормыш-көнкүрешен яхшыртуга юнәлдерелгән тотрыклы икътисади үсешне тәэмин итү максатыннан, эшмәкәрлек эшчәнлегенең өстенлекле төрләре билгеләнде:

- авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү;
- халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү;
- транспорт һәм элемтә өлкәсе;
- төзелеш;
- социаль хезмәт күрсәтү өлкәсе.

## 6. Программаның төп чаралары эшләнгән юнәлешләр

1. Кече һәм урта эшмәкәрлекне нәтиҗәле үстерү өчен хокукый базаны камилләштерү һәм административ киртәләрне киметү.
2. Кече һәм урта эшмәкәрлеккә мәгълүмати-консультацион ярдәм күрсәтү.
3. Зур Сәрдек авыл җирлеге эшмәкәренең уңай имиджын һәм җәмәгатьчелектә кече һәм урта эшмәкәрлек турында уңай фикер формалаштыру;
4. Кече эшмәкәрлек өчен квалификацияле кадрлар әзерләү.
5. Яшьләрнең һәм эшсезләрнең эшмәкәрлек башлангычын хуплау һәм стимуллаштыру.
6. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары белән хакимият органнары арасында партнерлык мөнәсәбәтләре урнаштыруга ярдәм итү.

## 7. Программаны тормышка ашыру механизмы

| | |
|---|---|
| Программа белән идарә итү | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| Программаны финанслау | Зур Сәрдек авыл җирлегенең кече бизнес субъектларының үз акчалары |
| Программаның төп башкаручылары | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| Программаның үтәлешен контрольдә тоту | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге Башкарма комитеты |

**8. Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясендә 2022 – 2025 елларга кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү Программасының төп чаралары**

| № т/б | Чаралар исемлеге | Нәтиҗә | Финанслау чыганагы | Үтәү вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 6 |
| 1. Эшмәкәрлекнең инновацион үсеше (инфраструктураны үстерү, инновацион потенциалны гамәлгә ашыру, яшьләрне инновацион процесска җәлеп итү) | | | | |
| 1 | Яшьләрне эшмәкәрлеккә җәлеп итүгә ярдәм итә торган чаралар комплексын уздыру, шул исәптән укыту, мәгълүмати тәэмин итү, конкурслар һәм ярышлар, ярминкәләр, конференцияләр, бизнес-фестивальләр һ. Б. ларны уздыру | Яшьләрне эшмәкәрлек эшчәнлегенә җәлеп итү. Яшь белгечләрне эшкә урнаштыру мәсьәләсен өлешчә хәл итү | Финанслаудан башка | 2022 – 2025 еллар |
| 2. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс-кредит һәм мөлкәт ярдәме күрсәтү | | | | |
| | Зур Сәрдек авыл җирлеге буенча кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына дәүләт ярдәме кысаларында чараларны гамәлгә ашыруда федераль һәм республика дәүләт хакимияте структураларына ярдәм итү | Эшмәкәрлекне үстерүгә юнәлдерелгән федераль һәм республика программаларында катнашучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары санын арттыру | Финанслаудан башка | 2022 – 2025 еллар |
| 2 | Зур Сәрдек авыл җирлеге икътисадының өстенлекле юнәлешләрен үстерү максатларында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына Зур Сәрдек авыл җирлеге буенча җир кишәрлекләре, торак булмаган биналар белән тәэмин итүдә булышу | Җирлек икътисадының өстенлекле юнәлешләрен үстерү максатларында кече һәм урта предприятиеләрне җир кишәрлекләре, торак булмаган сәүдә һәм җитештерү биналары белән тәэмин итү, районда үткәрелә торган тендерлар, | Финанслаудан башка | 2022 – 2025 еллар |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | аукционнар турында эшмәкәрләрнең хәбәрдарлыгын арттыру | | |
| 3 | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуларга җәлеп итү һәм стимуллаштыру | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуларга җәлеп итү һәм стимуллаштыру | Финанслаудан башка | 2022 – 2025 еллар |
| 3. Кече һәм урта эшмәкәрлеккә мәгълүмати-консультацион ярдәм күрсәтү. | | | | |
| 1 | Районда кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм аны үстерү өлкәсендә үткәрелә торган чараларны мәгълүмати яктан тәэмин итү (буклетлар әзерләү) | Кече һәм урта бизнес вәкилләренең алдынгы эш тәҗрибәсен системалаштыру һәм тарату. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге башкарма комитеты үткәргән конкурсларда, күргәзмәләрдә, башка чараларда катнашуга җәлеп итү | Финанслаудан башка | 2022 – 2025 еллар |
| 3. Эшмәкәрнең уңай имиджын һәм җәмәгатьчелектә кече һәм урта эшмәкәрлек турында уңай фикер формалаштыру | | | | |
| 1 | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе территориясендә үткәрелә торган күргәзмәләрдә, ярминкәләрдә, конкурсларда катнашуга җәлеп итү | Эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм итү, эшмәкәрлек эшчәнлегенең иң яхшы субъектлары эшенең алдынгы тәҗрибәсен тарату, Зур Сәрдек авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсешендә кече һәм урта бизнесның ролен һәм әһәмиятен пропагандалау | Финанслаудан башка | 2022 – 2025 еллар |